КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 26 июль г.Казань № б-1682

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 1 ноябрь, б-2182 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 гыйнвар, б-111 нче; 2022 ел, 22 август, б-1763 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында сәнәгать һәм сәүдә тармакларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Т.Җ.Сөләймановны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Татарстан агач эшкәртү комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Директорлар советы рәисе Александр Анатольевич Когогинны (килешү буенча);

«А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Яр Чаллы филиалы директоры Азат Филкать улы Мостафинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры Ринат Наил улы Садыйковны;

Рамил Хәмзә улы Муллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама муниципаль районы башлыгы (килешү буенча)»;

Юлия Дмитриевна Цветкованың вазыйфа исемен түбә

ндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ростех» дәүләт корпорациясенең персонал белән идарә итү директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин